# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Балан-Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

07 декабрь 2022 ел №1

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 07 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының протоколы төзелде:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Балан-Бүләк торак пунктында зиратларына коймa кую өчен төзелеш материаллары сатып алу ( зиратларны коймалап алу һәм урнаштыру, лак-буяу материалы сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Балан-Бүләк торак пунктында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Балан-Бүләк торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү «Җиңү көне», «Сабантуй», "Халыкара өлкәннәр көне» нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Балан-Бүләк торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эш өчен түләү, триммер өчен ГСМ и запас частьләр сатып алу, территорияләрне санитар чистарту буенча хезмәтләр, территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 79 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 44.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 44, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Балан-Бүләк торак пунктында зиратларына койма кую өчен төзелеш материаллары сатып алу ( зиратларны коймалап алу һәм урнаштыру, лак-буяу материалы сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Балан-Бүләк торак пунктында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Балан-Бүләк торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү «Җиңү көне», «Сабантуй», "Халыкара өлкәннәр көне» нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Балан-Бүләк торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эш өчен түләү, триммер өчен ГСМ и запас частьләр сатып алу, территорияләрне санитар чистарту буенча хезмәтләр, территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы ______________ (имза) А.М.Мөхәмәтшин (имза расшифровкасы)